**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Земельный кодекс**
**Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2016 года

**Статья 1**

Внести в Земельный кодекс Республики Татарстан (в редакции Закона Республики Татарстан от 18 января 2005 года № 4-ЗРТ) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 1998, № 8 (II часть); 1999, № 8 (I часть); 2005, № 1 (I часть), № 12 (I часть); 2006, № 7 (I часть); 2007, № 1 (I часть), № 4; 2008, № 5 (I часть); 2009, № 7 – 8 (III часть); 2010, № 11; 2011, № 11 (I часть); 2012, № 3, № 5 (I часть); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 7 (I часть), № 10 (I часть) следующие изменения:

1) в статье 3:
а) в подпункте 5 слова «, в том числе путем выкупа,» исключить;
б) дополнить подпунктом $6^2$ следующего содержания:
«$6^2$) установление порядка и условий размещения на землях или земельных участках, находящихся в государственной или муниципальной собственности, объектов, размещение которых может осуществляться без предоставления земельных участков и установления сервитутов и виды которых установлены Правительством Российской Федерации;»;

2) в подпункте 2 статьи 5 слова «, в том числе путем выкупа,» исключить;

3) подпункт 3 статьи 7 изложить в следующей редакции:
«3) земли промышленности, энергетики, транспорта, связи, радиовещания, телевидения, информатики, земли для обеспечения космической деятельности, земли обороны, безопасности и земли иного специального назначения;»;

4) в пункте 2 статьи 9 слова «древесно-кустарниковой растительностью, предназначенной» заменить словами «лесными насаждениями, предназначенными», слово «строениями,» исключить;

5) в статье 10:

а) в наименовании слова «и пригородные зоны» исключить;

б) пункты 4 – 8 признать утратившими силу;

в) пункт 10 изложить в следующей редакции:

«10. Земельные участки общего пользования, занятые площадями, улицами, проездами, автомобильными дорогами, набережными, скверами, бульварами, водными объектами, пляжами и другими объектами, могут включаться в состав различных территориальных зон и не подлежат приватизации.»;

6) в статье 11:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 11. **Земли промышленности, энергетики, транспорта, связи, радиовещания, телевидения, информатики, земли для обеспечения космической деятельности, земли обороны, безопасности и земли иного специального назначения**»;

б) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Землями промышленности, энергетики, транспорта, связи, радиовещания, телевидения, информатики, землями для обеспечения космической деятельности, землями обороны, безопасности и землями иного специального назначения признаются земли, которые расположены за границами населенных пунктов и используются или предназначены для обеспечения деятельности организаций и (или) эксплуатации объектов промышленности, энергетики, транспорта, связи, радиовещания, телевидения, информатики, объектов для обеспечения космической деятельности, объектов обороны и безопасности, осуществления иных специальных задач и права на которые возникли у участников земельных отношений по основаниям, предусмотренным законодательством (далее – земли промышленности и иного специального назначения).»;

7) в пункте 8 статьи 12 слова «, в том числе путем выкупа,» исключить;

8) пункт 2 статьи 15 изложить в следующей редакции:

«2. Использование земель запаса допускается после перевода их в другую категорию, за исключением случаев, если земли запаса включены в границы охотничьих угодий, случаев выполнения работ, связанных с пользованием недрами на таких землях, и иных предусмотренных федеральными законами случаев.»;

9) в пункте 2 статьи 18:

а) абзац первый после слов «постоянного (бессрочного) пользования,» дополнить словами «безвозмездного пользования,»;

б) в абзаце втором слово «срочного» исключить;

10) пункт 3 статьи 20 изложить в следующей редакции:

«3. В собственность муниципальных образований для обеспечения их развития могут безвозмездно передаваться земли, находящиеся в собственности

Республики Татарстан, в том числе за пределами границ муниципальных образований, а также земельные участки, находящиеся в собственности Республики Татарстан, в целях их предоставления отдельным категориям граждан и (или) некоммерческим организациям, созданным гражданами, в соответствии с подпунктами 6 и 7 статьи $39^5$ Земельного кодекса Российской Федерации.»;

11) в статье 21:

а) в наименовании слово «срочное» исключить;

б) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. В безвозмездное пользование могут предоставляться земельные участки:

1) находящиеся в государственной или муниципальной собственности, гражданам и юридическим лицам, определенным Земельным кодексом Российской Федерации, федеральными законами, настоящим Кодексом и иными законами Республики Татарстан, в том числе в виде служебного надела;

2) находящиеся в собственности граждан или юридических лиц, иным гражданам или юридическим лицам на основании договора, в том числе в виде служебного надела.»;

в) дополнить пунктом $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. Земельные участки, находящиеся в государственной или муниципальной собственности, предоставляются однократно в безвозмездное пользование на срок не более чем шесть лет для индивидуального жилищного строительства или ведения личного подсобного хозяйства гражданам, работающим по основному месту работы в городских или сельских поселениях, входящих в состав муниципальных районов Республики Татарстан:

1) в образовательных организациях по специальностям: «педагогическое образование», «дошкольное образование», «преподавание в начальных классах», «педагогика дополнительного образования»;

2) в медицинских организациях по специальностям: «лечебное дело», «акушерское дело», «сестринское дело»;

3) в сельскохозяйственных организациях по специальностям: «агрономия», «ветеринария», «зоотехния», «агроинженерия», «механизация сельского хозяйства».»;

г) в абзаце первом пункта 2 слово «срочное» исключить;

д) в абзаце первом пункта 3 слова «из земель, находящихся в собственности Республики Татарстан,» исключить;

12) подпункт 7 пункта 3 статьи 25 изложить в следующей редакции:

«7) сохранению плодородия почв и их использованию при проведении работ, связанных с нарушением земель.»;

13) в абзаце третьем пункта 1 статьи 30 слово «, пригородными» исключить;

14) в статье 32:

а) пункт 2 признать утратившим силу;

б) в пункте 3:

в абзаце первом слова «муниципальной собственности, а также из земель, государственная собственность на которые не разграничена» заменить словами «государственной или муниципальной собственности»;

в подпункте 1 слова «и предварительного согласования мест размещения объектов» исключить;

в) пункты 4 – 6 признать утратившими силу;

15) в статье $32^1$:

а) пункт 5 изложить в следующей редакции:

«5. Гражданам, заинтересованным в предоставлении земельных участков для целей, указанных в подпункте 1 пункта 3 статьи 32 настоящего Кодекса, постоянно проживающим на территории городского округа, земельные участки предоставляются в границах соответствующего городского округа или, с их согласия, из числа расположенных на территории иных муниципальных образований земельных участков, которые находятся в собственности городского округа или полномочия по управлению и распоряжению которыми осуществляются Республикой Татарстан.»;

б) в абзаце первом пункта 8 слова «находящихся в муниципальной собственности, а также земельных участков, государственная собственность на которые не разграничена,» исключить;

в) дополнить пунктом $14^1$ следующего содержания:

«$14^1$. Решение о предоставлении земельного участка, полномочия по управлению и распоряжению которым осуществляются Республикой Татарстан, принимается уполномоченным органом исполнительной власти на основании акта, указанного в пункте 13 настоящей статьи, не позднее 30 дней с момента его подписания.»;

г) дополнить пунктом $19^1$ следующего содержания:

«$19^1$. Порядок взаимодействия уполномоченного органа исполнительной власти и органов местного самоуправления городских округов при предоставлении земельных участков в соответствии с пунктом 5 настоящей статьи устанавливается Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

16) статью $33^1$ признать утратившей силу;

17) в статье 34:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 34. **Предельные (минимальные и максимальные) размеры земельных участков**»;

б) в абзаце первом пункта 1 слова «собственности Республики Татарстан» заменить словом «государственной»;

в) в абзаце первом пункта 2 слова «собственности Республики Татарстан» заменить словом «государственной»;

г) пункт 3 признать утратившим силу;

д) в пункте 4 второе предложение исключить;

е) пункты 5 и 6 признать утратившими силу;

18) в статье 36:

а) в пункте 1 слова «в силу принудительного изъятия у собственника его земельного участка в порядке, установленном гражданским законодательством» заменить словами «, по иным основаниям, предусмотренным гражданским и земельным законодательством»;

б) в пункте 2:

в абзаце первом слова «установленных Земельным кодексом Российской Федерации» заменить словами «которые предусмотрены Земельным кодексом Российской Федерации и по иным основаниям, установленным гражданским и земельным законодательством»;

абзац второй изложить в следующей редакции:

«Право постоянного (бессрочного) пользования земельным участком, право пожизненного наследуемого владения земельным участком прекращаются принудительно по основаниям и в порядке, установленным Земельным кодексом Российской Федерации.»;

19) в статье 37:

а) в наименовании слова «, в том числе путем выкупа,» исключить;

б) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Изъятие земельных участков для государственных нужд Республики Татарстан или муниципальных нужд осуществляется в исключительных случаях, установленных Земельным кодексом Российской Федерации и федеральными законами.»;

в) в пункте 2 слова «и муниципальных» заменить словами «или муниципальных»;

г) пункт 3 признать утратившим силу;

20) статью $37^1$ признать утратившей силу;

21) в статье 38:

а) в наименовании слова «изъятии земельных участков для государственных или муниципальных нужд,» исключить;

б) в тексте слова «изъятии земельных участков для государственных или муниципальных нужд,» исключить;

22) в статье 43:

а) пункт 1 дополнить словами «и случаев изъятия земельного участка для государственных или муниципальных нужд»;

б) в абзаце первом пункта 2 слово «девяносто» заменить цифрами «90»;

в) в абзаце четвертом пункта 3 слово «тридцати» заменить цифрами «30»;

23) в статье 44:

а) в наименовании слова «собственности Республики Татарстан» заменить словом «государственной»;

б) в пункте 1 слова «собственности Республики Татарстан» заменить словом «государственной»;

в) пункт 2 изложить в следующей редакции:

«2. Земельный участок, предназначенный для ведения сельскохозяйственного производства и переданный в аренду гражданину или юридическому лицу, может быть приобретен в собственность без торгов этим гражданином или этим юридическим лицом по истечении трех лет с момента заключения договора аренды с этим гражданином или этим юридическим лицом либо передачи прав и обязанностей по договору аренды земельного участка этому гражданину или этому юридическому лицу при условии надлежащего использования такого земельного участка в случае, если этим гражданином или этим юридическим лицом заявление о заключении договора купли-продажи такого земельного участка без проведения торгов подано до дня истечения срока указанного договора аренды земельного участка.»;

г) пункт 3 признать утратившим силу;

24) в статье 45:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 45. **Публикация сообщений, связанных с оборотом земельных участков из земель сельскохозяйственного назначения, долей в праве общей собственности на земельные участки из земель сельскохозяйственного назначения, в средствах массовой информации**»;

б) пункт 1 статьи 45 изложить в следующей редакции:

«1. В средствах массовой информации, определяемых Кабинетом Министров Республики Татарстан, публикуются следующие сообщения, связанные с оборотом земельных участков из земель сельскохозяйственного назначения, долей в праве общей собственности на земельные участки из земель сельскохозяйственного назначения:

1) информация о возможности приобретения земельного участка, выделенного в счет земельных долей, находящихся в муниципальной собственности;

2) информация о возможности приобретения земельной доли, находящейся в муниципальной собственности;

3) список невостребованных земельных долей;

4) извещение о месте и порядке ознакомления с проектом межевания земельных участков;

5) извещение о необходимости согласования проекта межевания земельных участков;

6) извещение участников долевой собственности о предстоящем общем собрании участников долевой собственности.»;

25) статью 46 признать утратившей силу.

**Статья 2**

Признать утратившими силу:

1) подпункты «а» и «б» пункта 4, пункт 12 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 31 июля 2009 года № 41-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 7 – 8 (III часть); 2014, № 5);

2) подпункт «б» пункта 1 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 17 мая 2012 года № 22-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 5 (I часть);

3) пункт 6 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 14 мая 2014 года № 36-ЗРТ «О внесении изменений в Земельный кодекс Республики Татарстан и признании утратившими силу отдельных положений законодательных актов Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 5);

4) Закон Республики Татарстан от 23 июля 2014 года № 68-ЗРТ «О внесении изменения в Земельный кодекс Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 7).

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию настоящего Закона, в течение трех месяцев со дня вступления в силу настоящего Закона.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ *
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
7 мая 2016 года
№ 32-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 5 пунктчада “, шул исәптән сатып алу” сүзләрен төшереп калдырырга;
б) түбәндәге эчтәлекле $6^2$ пунктча өстәргә:
“$6^2$) җир кишәрлекләре бирмичә һәм сервитутлар куймыйча урнаштырыла алган һәм төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән объектларны дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдә йә җир кишәрлекләрендә урнаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү;”;

2) 5 статьяның 2 пунктчасында “, шул исәптән сатып алу юлы белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 7 статьяның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“3) сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат җирләре, космик эшчәнлек тәэмин итәлә торган җирләр, оборона, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр;”;

4) 9 статьяның 2 пунктында “билгеләнгән агач-куаклыклар” сүзләрен “билгеләнгән урман утыртмалары” сүзләренә алмаштырырга, “төзелмәләр,” сүзен

төшереп калдырырга;

5) 10 статьяда:
а) исемендә “һәм шәһәр яны зоналары” сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 4 – 8 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;
в) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“10. Мәйданнар, урамнар, тыкрыклар, автомобиль юллары, төзекләндерелгән яр буйлары, скверлар, бульварлар, су объектлары, пляжлар һәм башка объектлар били торган гомуми кулланылыштагы җир кишәрлекләре төрле территориаль зоналар составына кертелергә мөмкин һәм хосусыйлаштырылырга тиеш түгел.”;

6) 11 статьяда:
а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“11 статья. **Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат җирләре, космик эшчәнлек тәэмин итәлә торган җирләр, оборона, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр**”;
б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Торак пунктлар чикләреннән читтә урнашкан һәм сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат объектлары, космик эшчәнлекне тәэмин итә торган объектлар, оборона һәм иминлек объектлары оешмалары эшчәнлеген һәм (яисә) аларны эксплуатацияләүне тәэмин итү, башка махсус бурычларны үтәү өчен файдаланыла торган яисә шуның өчен каралган һәм җир мөнәсәбәтләрендә катнашучыларның законнарда каралган нигезләрдә хокуклары барлыкка килгән җирләр сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, мәгълүмат җирләре, космик эшчәнлек тәэмин ителә торган җирләр, оборона, иминлек җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр (алга таба – сәнәгать җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр) булып танылa.”;

7) 12 статьяның 8 пунктында “шул исәптән сатып алу юлы белән,” сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 15 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Запас җирләрдән файдалану аларны башка категориягә күчергәннән соң рөхсәт ителә, моңа запас җирләрнең аучылык җирләре чикләрендә урнашу очраклары, мондый җирләрдә җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкару очраклары һәм федераль законнарда каралган башка очраклар керми.”;

9) 18 статьяның 2 пунктында:
а) беренче абзацта “даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану,” сүзләреннән соң “түләүсез файдалану,” сүзләрен өстәргә;
б) икенче абзацта “вакытлыча” сүзен төшереп калдырырга;

10) 20 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Татарстан Республикасы милкендәге, шул исәптән муниципаль берәмлекләр чикләреннән читтә урнашкан җирләр, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре муниципаль берәмлекләрнең үсешен тәэмин итү өчен гражданнарның аерым категорияләренә һәм (яисә) гражданнар тарафыннан төзелгән коммерциячел булмаган оешмаларга бирү максатларында Россия Федерациясе Җир кодексының $39^5$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктчалары нигезендә муниципаль берәмлекләр милкенә түләүсез тапшырылырга мөмкин.”;

11) 21 статьяда:

а) исемендә “вакытлыча” сүзен төшереп калдырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Түләүсез файдалануга түбәндәге җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин:

1) дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән – Россия Федерациясе Җир кодексында, федераль законнарда, әлеге Кодекста һәм Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән гражданнарга һәм юридик затларга, шул исәптән хезмәт урыныннан вакытлыча бирелгән җир кишәрлеге рәвешендә;

2) гражданнар яисә юридик затлар милкендәге җирләрдән – шартнамә нигезендә башка гражданнарга яисә юридик затларга, шул исәптән хезмәт урыныннан вакытлыча бирелгән җир кишәрлеге рәвешендә.”;

в) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

“$1^1$. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләре Татарстан Республикасы муниципаль районнары составына керә торган шәһәр яисә авыл җирлекләрендә төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга индивидуаль торак төзелеше яисә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен алты елдан да артмаган вакытка түләүсез файдалануга бер мәртәбә бирелә:

1) мәгариф оешмаларында “педагогик белем”, “мәктәпкәчә белем”, “башлангыч классларга белем бирү”, “өстәмә белем бирү педагогикасы” белгечлекләре буенча;

2) медицина оешмаларында “дәвалау эше”, “акушерлык”, “шәфкать туташы” белгечлекләре буенча;

3) авыл хуҗалыгы оешмаларында “агрономия”, “ветеринария”, “зоотехния”, “агроинженерия”, “авыл хуҗалыгын механикалаштыру” белгечлекләре буенча.”;

г) 2 пунктның беренче абзацында “вакытлыча” сүзен төшереп калдырырга;

д) 3 пунктның беренче абзацында “Татарстан Республикасы милкендәге җирләрдән” сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 25 статьяның 3 пунктындагы 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7) җирләр бозылуга китерә торган эшләр башкарганда туфракның уңдырышлылыгын саклап калу һәм аннан файдалану.”;

13) 30 статьяның 1 пунктындагы өченче абзацында “, шәһәр яны” сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 32 статьяда:

а) 2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) 3 пунктта:

беренче абзацта “Муниципаль милектәге җирләрдән, шулай ук үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән” сүзләрен “Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге” сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктчада “һәм объектларны урнаштыру урыннарын алдан килештермичә” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 4 – 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

15) $32^1$ статьяда:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5. Әлеге Кодексның 32 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән максатлар өчен җир кишәрлекләре алырга теләгән шәһәр округы территориясендә даими яши торган гражданнарга җир кишәрлекләре тиешле шәһәр округы чикләрендә яисә, аларның ризалыгы белән, шәһәр округы милкендәге яисә идарә итү һәм эш йөртү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы гамәлгә ашыра торган башка муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашкан җир кишәрлекләреннән бирелә.”;

б) 8 пунктның беренче абзацында “муниципаль милектәге җир кишәрлекләре, шулай ук үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ пункт өстәргә:

“$14^1$. Идарә итү һәм эш йөртү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы гамәлгә ашыра торган җир кишәрлекләрен бирү турында карар әлеге статьяның 13 пунктында күрсәтелгән акт нигезендә имза салынганнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан кабул ителә.”;

г) түбәндәге эчтәлекле $19^1$ пункт өстәргә:

“$19^1$. Әлеге статьяның 5 пункты нигезендә җир кишәрлекләре бирелгәндә башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары арасындагы хезмәттәшлек тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.”;

16) $33^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 34 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“34 статья. **Җир кишәрлекләренең иң чик (минималь һәм максималь) күләмнәре**”;

б) 1 пунктның беренче абзацында “Татарстан Республикасы милкендәге” сүзләрен “Дәүләт милкендәге” сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 пунктның беренче абзацында “Татарстан Республикасы милкендәге” сүзләрен “Дәүләт милкендәге” сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

д) 4 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

е) 5 һәм 6 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

18) 36 статьяда:

а) 1 пунктта “милекчедән аның җир кишәрлеген мәҗбүри рәвештә тартып алу нәтиҗәсендә милекче граждан законнарында билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “милекче граждан һәм җир законнарында каралган башка нигезләрдә” сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта:

беренче абзацта “Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә” сүзләрен “Россия Федерациясе Җир кодексында каралган шартларда һәм тәртиптә, граждан һәм җир законнарында билгеләнгән башка нигезләрдә” сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукы, җир кишәрлеген мирас итеп калдырырлык гомерлек биләү хокукы Россия Федерациясе Җир кодексында билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә мәҗбүри туктатыла.”;

19) 37 статьяда:

а) исемендә “, шул исәптән сатып алу” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен аерып алу Россия Федерациясе Җир кодексында һәм федераль законнарда билгеләнгән аерым очракларда гына гамәлгә ашырыла.”;

в) 2 пунктта “һәм муниципаль” сүзләрен “яисә муниципаль” сүзләренә алмаштырырга”;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

20) $37^1$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

21) 38 статьяда:

а) исемендә “Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен аерып алганда,” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) текстта “Дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен аерып алганда,” сүзләрен төшереп калдырырга;

22) 43 статьяда:

а) 1 пунктта “сату очракларыннан” сүзләреннән соң “һәм җир кишәрлеген дәүләт ихтыяҗлары яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен аерып алу очракларыннан” сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктның беренче абзацында “туксан” сүзен “90” саннарына алмаштырырга;

в) 3 пунктның дүртенче абзацында “утыз” сүзен “30” саннарына алмаштырырга;

23) 44 статьяда:

а) исемендә “Татарстан Республикасы” сүзләрен “Дәүләт” сүзенә алмаштырырга;

б) 1 пунктта “Татарстан Республикасы” сүзләрен “Дәүләт” сүзенә алмаштырырга;

в) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен билгеләнгән һәм гражданга яисә юридик затка арендага бирелгән җир кишәрлеге, әлеге граждан яисә әлеге юридик зат мондый җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә сату-алу шартнамәсен төзү турындагы гаризаны җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсенең срогы тәмамланачак көнгә кадәр биргән очракта, әлеге граждан яисә әлеге юридик зат белән аренда килешүе төзелгән йә җир кишәрлеген арендалауның күрсәтелгән шартнамәсе буенча хокуклар һәм йөкләмәләр әлеге гражданга яисә әлеге юридик затка тапшырылган вакыттан соң өч ел үткәч, мондый җир кишәрлегеннән тиешенчә файдалану шарты белән, әлеге граждан яисә әлеге юридик зат тарафыннан милеккә сатып алынырга мөмкин.”;

г) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

24) 45 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“45 статья. **Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләре әйләнешенә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләренә гомуми милек хокукындагы өлешләр әйләнешенә бәйле хәбәрләрне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару**”;

б) 45 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган массакүләм мәгълүмат чараларында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләре әйләнешенә, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән булган җир кишәрлекләренә гомуми милек хокукындагы өлешләр әйләнешенә бәйле түбәндәге хәбәрләр бастырып чыгарыла:

1) муниципаль милектәге җир өлешләре исәбеннән бүлеп бирелгән җир кишәрлеге сатып алу мөмкинлеге турында мәгълүмат;

2) муниципаль милектәге җир өлеше сатып алу мөмкинлеге турында мәгълүмат;

3) файдаланылмый торган җир өлешләре исемлеге;

4) җир кишәрлекләрен ызанлау проекты белән танышу урыны һәм тәртибе турында хәбәр;

5) җир кишәрлекләрен ызанлау проектын килештерү зарурлыгы турында хәбәр;

6) өлешле милектә катнашучыларның гомуми җыелышы булачагы турында өлешле милектә катнашучыларга хәбәр итү.”;

25) 46 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2009 елның 31 июлендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 4 пунктының “а” һәм “б” пунктчалары, 12 пункты (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2014, № 5);

2) “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 2012 елның 17 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының “б” пунктчасы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 5 (I өлеш);

3) “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында” 2014 елның 14 маендагы 36-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 6 пункты (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 5);

4) “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәреш кертү турында” 2014 елның 23 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 7);

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                 Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 7 мае
№ 32-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ